| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**20.12.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2685** |

Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтер) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау турында

1995 елның 11 августындагы«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 135-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2018 елның 21 июнендәге«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтер) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2685 номерлы карары белән

расланды

**Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтер) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе**

1. Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеге дигәндә, әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларда эшләрне түләүсез башкару формасында һәм (яисә) хезмәтләр күрсәтүнең ихтыярый эшчәнлеге аңлашыла.

2. Җирле үзидарә органнары ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга ихтыярый ярдәм итүчеләрне (волонтерларны) ) җәлеп итәргә хокуклы.

3. Ихтыярыйлык(волонтерлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

социаль ярдәм һәм гражданнарны яклау, шул исәптән аз керемлеләрнең матди хәлен яхшырту, эшсезләрне, инвалидларны һәм үзләренең физик яки интеллектуаль үзенчәлекләре аркасында үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен мөстәкыйль рәвештә тормышка ашыра алмыйлар торган башка затларны социаль реабилитацияләү;

халыкны табигать афәтләре, экологик, сәнәгать яки башка катастрофалар нәтиҗәләрен җиңәргә, бәхетсезлек очракларын булдырмый калуга әзерләү;

табигать афәтләре, экологик, сәнәгать яки башка катастрофалар, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргәннәргә, репрессия корбаннарына, качакларга һәм мәҗбүри күченеп китүчеләргә ярдәм күрсәтү;

халыклар арасында тынычлыкны, дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга, социаль, милли, дини конфликтларны булдырмый калуга булышлык күрсәтү;

җәмгыятьтә гаиләнең абруен һәм ролен ныгытуга ярдәм итү;

ана, балачак һәм ата-ананы яклауга булышу;

мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге эшчәнлеккә, шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү;

гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның әхлакый-психологик халәтен яхшырту;

физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлеккә (һөнәри спорттан тыш), эшләрне түләүсез башкару һәм (яисә) физик затлар тарафыннан хезмәт күрсәтү рәвешендә физкультура һәм спорт чараларын оештыруда һәм (яисә) уздыруда катнашуга булышлык күрсәтү;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау;

тарихи, культ, мәдәни яки табигать саклау әһәмияте булган биналарны, объектларны һәм территорияләрне һәм җирләү урыннарын саклау һәм тиешле тоту;

халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, караучысыз калган балаларны, авыр тормыш хәлендә калган балаларны социаль реабилитацияләү;

халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый белем бирү;

ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү;

балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашу;

балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник, сәнгать иҗатын үстерүгә ярдәм итү;

балаларны һәм яшьләрне патриотик, рухи-әхлакый тәрбияләүгә ярдәм итү;

иҗтимагый әһәмиятле яшьләр инициативаларына, проектларына, балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә, балалар һәм яшьләр оешмаларына ярдәм итү;

социаль реклама җитештерү һәм (яисә) тарату эшчәнлегенә ярдәм итү;

гражданнарның социаль куркыныч тәртип формаларын профилактикалауга ярдәм итү.

4. Үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатыннан ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар муниципаль учреждениеләргә ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча язма тәкъдим җибәрергә хокуклы.

Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының тәкъдимнәре түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) һәм аның җитәкчелеге һәм вәкилләре элемтәсен, ә юридик затлар өчен - атамасын һәм дәүләт теркәве турында белешмәне;

- “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайт адресын;

- эшчәнлек төрләрен тасвирлап, аларны гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән исемлек.

5. Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының күрсәтелгән тәкъдимнәрен карау срогы 20 эш көненнән артып китә алмый.

6. Муниципаль учреждение тарафыннан ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының тәкъдимнәрен карау нәтиҗәләрен рәсмиләштерү уртак эшчәнлек турында килешү проекты кушылып бирелергә тиешле хуплау турында карар чыгару яисә муниципаль учреждение хаты белән рәсмиләштерелә торган тәкъдимнән баш тарту рәвешендә (мөмкинлек булганда электрон почта аша)бер көн эчендә ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы адресына җибәрелеп башкарылырга тиеш.

7. Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, муниципаль учреждение тарафыннан ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимнәре кире кагылган очракта, муниципаль

учреждениене оештыручы (гамәлгә куючы) булган җирле үзидарә органына шундый ук тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы

8. Ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмалары муниципаль учреждениеләр белән уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә хокуклы.

9. Килешүне карау срогы ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тәкъдимне хуплау турында карар алган көннән башлап 14 эш көненнән артып китә алмый.

10. Уртак эшчәнлек турында килешү төзү барышында барлыкка килә торган муниципаль учреждение һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) оешма арасында каршылыклар барлыкка килгән очракта, ихтыярый (волонтерлык) оешмасын оештыручы яисә учреждение муниципаль учреждениене оештыручы (гамәлгә куючы) булып торган җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

11. Муниципаль учреждение һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) оешма арасында уртак эшчәнлек турында килешү төзегәндә, учреждение ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтерлар) һәм ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручы вәкилләре белән үзара хезмәттәшлек өчен җаваплы хезмәткәр билгеләп куярга тиеш.

12. Ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы һәм учреждениенең уртак эшчәнлеге турында килешү, гамәлгә ашырыла торган ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенең үзенчәлеген, уртак эшчәнлекнең предметын һәм максатларын, якларның хокукларын һәм бурычларын, шул исәптән, түбәндәге нигезләмәләрне билгеләүне күздә тотарга тиеш:

а)ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының учреждение территориясендә һәм биналарында, учреждение белән килешенгән эшчәнлек формаларында гамәлгә ашыру хокукын;

б) ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы вазыйфаларын:

- җәлеп ителгән белгечләрнең, хезмәткәрләрнең һәм/яисә ихтыярый ярдәм итүчеләрнең (волонтерларның) исемлеген, аларның фамилияләрен, исемен, атасының исемен күрсәтеп, учреждениегә кирәк булганда башка мәгълүматлар (яклар килешүе буенча) тәкъдим итәргә, шул исәптән махсус һөнәри күнекмәләр булу турында;

- вәкаләтле вәкилне билгеләргә һәм язма мөрәҗәгатьтә шул турыда учреждениегә хәбәр итәргә;

- килешүне үтәү нәтиҗәсендә мәгълүм булган конфиденциаль һәм шәхси мәгълүматка карата таләпләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлешен тәэмин итәргә;

- учреждение эшен регламентлаучы хокукый нормаларны, шул исәптән учреждениенең эчке тәртибе кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- учреждение биргән биналарны, саклау урыннарын, техник чараларны, җиһазларны тиешле санитар-гигиена хәлендә карап тотарга;

-учреждение белән аның территориясендә һәм аның клиентлары катнашында гамәлгә ашыру планлаштырылган чараларны үткәрү планын килештерергә;

- башкарылган эшләр һәм чаралар уздыру йомгаклары турындагы хисапларны учреждениегә тапшырырга;

- ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген башкарганда ихтыярый ярдәм итүчеләрнең( волонтерның) тормышына һәм сәламәтлегенә китерелгән зыянны каплауны тәэмин итү;

в) учреждение хокуклары:

- ихтыярыйлык(волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга ихтыярый ярдәм итүчеләрне (волонтерларны) җәлеп итүгә ихтыяҗ турында хәбәр итәргә;

- ихтыярыйлык(волонтерлык) оештыручы эшчәнлегенә , ихтыярый ярдәм итүчеләргә (волонтерларга) булышуны тәэмин итәргә;

г) учреждение бурычлары:

- ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтерлар) эшчәнлеген тәэмин итү өчен биналар, шулай ук техник чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итәргә;

- ихтыярыйлык(волонтерлык) эшчәнлеген тәүлек әйләнәсе яки билгеләнгән вакыт аралыгында гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләр һәм шартлар тудыруны тәэмин итәргә;

- ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының хезмәттәшлеге турында килешү төзелгәнче, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр һәм куркынычлар, учреждение эшен регламентка сала торган хокукый нормалар, кирәкле режим таләпләре һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга үтәлергә тиешле башка кагыйдәләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, шулай ук бу нормалар һәм кагыйдәләр үзгәрүе турында вакытында хәбәр итәргә ;

- уртак эштә барлыкка килә торган мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен ихтыярыйлык(волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы вәкилләре белән эшләү буенча вәкаләтле хезмәткәрне билгеләргә;

д) йомгаклау нигезләмәләре:

-ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының һәм учреждениенең бурычлары килешүне үтәгәндә килеп туган проблемалар һәм кыенлыклар турында бер-берсен вакытында хәбәр итү, шулай ук ихтыярыйлык(волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының эшчәнлеге нәтиҗәләрен уртак фикер алышу һәм бәяләү;

- килешүне гамәлгә кертү, озайту һәм өзү, бәхәсләрне хәл итү шартлары, шул исәптән, кирәк булганда, учреждениене оештыручы (гамәлгә куючы) булган җирле үзидарә органнарын җәлеп итү.

13. Җирле үзидарә органнары «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законда, «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 21 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларында каралган формаларда ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итүне гамәлгә ашыра.